СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.04.2020 с. Верхний Услон № 57-655

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Югары әзерлек, гадәттән тыш хәл, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш һәм хәрби хәл чорларында җирле үзидарә вәкиллекле органының - Югары Ослан муниципаль районы Советының даими эшләвен тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Советы
карар итте:

1.1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 2016 елның 14 мартындагы 9-78 номерлы карары белән расланган Регламентына (алга таба-Регламент), түбәндәге эчтәлектәге $15^1$ бүлек белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«$15^1$ бүлек. Югары Ослан муниципаль районы Советының гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл режимы чорында эш үзенчәлекләре

Статья $79^1$

1. Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл кертелгән чорда район Башлыгы тарафыннан район Советы эшенең аерым тәртибе билгеләнә (алга таба – эшнең аерым тәртибе).

2. Әлеге Регламентның район Советы, район Советының даими комиссияләре утырышлары, тавыш бирү һәм аларда карарлар кабул итү өлешендә әлеге Регламентның аерым тәртибен билгеләгәндә әлеге бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.

3. Район Советы утырышы, район Советының даими комиссияләре утырышлары мәгълүмати-телекоммуникацион элемтә челтәрләрен кулланып, видеоконференцэлемтә рәвешендә (алга таба – район Советы утырышы, дистанцион формада район Советының даими комиссияләре) үткәрелергә мөмкин.

Статья $79^2$

1. Район Советының даими комиссиясе утырышын дистанцион рәвештә уздыру турында карар район Советы рәисенең мәҗбүри хәбәре белән даими комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

2. Әлеге комиссия әгъзалары булмаган затларның дистанцион рәвештә район Советының даими комиссиясе утырышында катнашуы район Советының даими комиссиясе рәисе карары буенча гамәлгә ашырыла.

3. Район Советының даими комиссиясе карарлары дистанцион рәвештә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу утырышта катнашучы район Советының даими комиссиясе әгъзаларын сораштыру (кулны күтәрү) юлы белән үткәрелә.

Статья $79^3$

1. Район Советы утырышында катнашу мөмкинлеге район Башкарма комитеты җитәкчесе, район прокуроры тарафыннан мәҗбүри тәртиптә тәэмин ителә.

2. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турындагы мәгълүмат аны үткәрү алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча район Советы депутатларына җибәрелә һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Район Советы утырышында карарлар дистанцион рәвештә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу, чыгышка язылу утырышта катнашучы депутатлардан сораштыру (кулны күтәрү) юлы белән башкарыла.

4. Район Советы утырышын дистанцион формада Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм кирәк булган очракта, шулай ук «Интернет» челтәрендәге башка мәгълүмати ресурсларда трансляцияләү мөмкин.

5. Чакырылган затлар, элемтәнең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып, дистанцион рәвештә район Советы утырышында катнаша.

Статья $79^4$

1. Район Советы утырышы, район Советының даими комиссиясе утырышы дистанцион формада үткәрелгәндә, утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

2. Район Советы утырышы беркетмәсенә, районның даими комиссиясенә дистанцион формада утырышны үткәргәндә, утырышның башлану һәм тәмамлану вакыты, үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары турында белешмәләр, шулай ук әлеге Регламентта каралган башка белешмәләр кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио-видеоязмасы кушымта итеп бирелә.

3. Югары Ослан муниципаль районы Советы Регламенты текстын яңа редакциядә расларга (1 кушымта)

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан районы муниципаль районы Советының 2020 елның 29 апрелендәге 57-655 номерлы карарына

1 кушымта

# Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы Регламенты

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

Статья 1.

1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы (алга таба - район Советы) эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен җайга сала, район Советы утырышларын чакыру, әзерләү һәм үткәрү тәртибен билгели, аның утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча карарлар тикшерү һәм кабул итү тәртибен билгели, даими комиссияләр, депутат төркемнәре, район Советының башка органнарының формалашуын һәм вәкаләтлекләрен билгели, район Советы һәм аның депутатларының үз вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле башка мәсьәләләрне җайга сала.

2. Әлеге Регламентны үтәү район Советы депутатлары өчен, муниципаль районның җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләре өчен, аның утырышларында катнашкан, депутатларның мөрәҗәгатьләрен һәм теләкләрен карап тикшерүдә катнашучы район Советы карауына сорауларын керткән башка шәхесләр өчен мәҗбүри булып тора.

Статья 2

1. Район Советы эшчәнлеге мәсьәләләрне хәл итүнең һәм фикер алышуның күмәк һәм ирекле принципларына нигезләнә.

Статья 3

1. Район Советы эшчәнлегенең төп формасы булып аның утырышларында район Советы компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү тора.

2. Район Советы утырышлары ачык һәм белдереп үткәрелә.

3. Район Советы ябык утырыш үткәрү турында карар кабул итә ала.

Статья 4

1. Район Советы, аның даими комиссияләре, район Советы депутатлары, район Советы рәисе -район Башлыгы һәм аның урынбасарының хокукый, оештыру, документаль, мәгълумати, материаль - техник эшчәнлекләрен тәэмин итүне Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты турында Кагыйдәнамәгә туры китереп район Советы Аппараты тормышка ашыра.

## 2 бүлек. Район Советы депутаты.

Статья 5

1. Район Совет депутаты вәкаләтләре аны җирлекнең сайлап куелган органы депутатлары арасыннан җирлек Башлыгы яки район Советы депутаты итеп сайлап куйган көннән башлана һәм яңа чакырылыш район Советы эшен башлаган көннән туктатыла.

2. Депутат үзенең эшчәнлеген федераль һәм республика кануннары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының депутат статусы турында Кагыйдәнамәсенә туры китереп тормышка ашыра.

Статья 6

1. Депутат берләшмәләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35.1 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясы нигезендә төзелә.

Статья 7

1. Депутат оешмаларын теркәү өчен район Советы рәисенә - район Башлыгына түбәндәге документларны җибәрәләр:

а) депутат оешмасы җитәкчесенең депутат берләшмәсе оешу турында язмача белдерү хаты;

б) депутат оешмасының аның оешу максатын, рәсми исемен, исемлек составын, шулай ук депутат оешмасы исеменнән чыгыш ясаучы һәм район Советы һәм аның органнары утырышларында аны тәкъдим итүче вәкаләтле затлар турында оештыру җыелышы беркетмәсе;

в) район Советы депутатларының депутат оешмасына керү турында язмача гаризасы.

2. Теркәү узган барлык депутат оешмалары район Советының депутат оешмалары Реестрына кертелергә тиеш.

3. Бу статья белән туры китереп, регистрация узмаган депутат оешмалары, бу Регламент белән билгеләнгән депутат хокуклары белән файдаланмый.

Статья 8

1. Депутат оешмалары хокуклы:

а) Район Башлыгын – район Советы рәисен һәм район Башлыгы урынбасарын – район Советы рәисе урынбасарын сайлау өчен кандидатураларны алдан тикшерергә;

б) район Советында карап тикшерелгән мәсьәләләр буенча фикер алышу үткәрергә;

в) башка фракцияләр, депутат төркемнәре белән консультация һәм башка килешү чаралары үткәрергә;

г) район Советы депутатлары арасында үзенең программаларын, тәкъдимнәрен, мөрәҗәгатьләрен һәм башка материалларны таратырга;

д) теләсә кайсы тикшерелә торган мәсьәлә буенча район Советы утырышында чыгыш ясарга;

е) үзенең вәкилләрен вакытлы депутат төркемнәренә, эшче төркемнәргә, шул исәптән килешү төркемнәренә кертергә;

ж) үзенең фракцияләр һәм депутат төркемнәре арасыннан район Советының теләсә кайсы урынына сайлану өчен кандидатуралар тәкъдим итергә;

з) канун белән тыелмаган теләсә кайсы эшчәнлекне тормышка ашырырга.

2. Уртак карарлар хәзерләү өчен, төрле фракцияләр һәм депутат төркемнәре вәкилләре тарафыннан берләштерелгән консультацияләр, киңәшмәләр, утырышлар үткәрелә ала.

Статья 9

1. Депутат оешмалары үз-үзләрен тарату турында карар кабул итә ала. Депутат оешмалары үз-үзләрен тарату турында карар кабул иткән очракта, ул депутат оешмасы җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм 3 көн эчендә муниципаль район Башлыгына җибәрелә.

2. Район Советы депутаты язмача гариза нигезендә теләсә кайсы вакытта депутат оешмасы составыннан чыга ала. Оешманың җитәкче ( координацияләүче) органы район Башлыгына оешма составы үзгәрүе турында состав үзгәргән вакыттан соң 5 көн эчендә хәбәр итәргә тиеш.

3. Бу Регламент белән туры китереп теркәү узган депутат оешмасының вәкилләре саны район Советының 5тән әзрәк депутаты булса, мондый депутат оешмасы район Советы депутат оешмалары реестрыннан чыгарыла, бу турыда район Башлыгы – район Советы рәисе район Советының алдагы утырышында депутатларга хәбәр итә.

## 3 бүлек. Район Башлыгын, район Башлыгы урынбасарын сайлау.

Статья 10

1. Район Башлыгы яңа сайланган район Советының беренче утырышында район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән район Советы вәкаләте вакытына сайлана. Район Башлыгы район Советы рәисе вазифаларын башкара.

2. Район Башлыгын сайлау район Советы депутатлары күрсәткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән район составына кергән авылларның сайлап куелган органнары, район халкы, иҗтимагый оешмалар, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә сайлана.

3. Район Башлыгы вазифасына сайлану өчен тәкъдим ителгән депутат үз кандидатурасын кире алырга хокуклы.

Статья 11

1. Үз кандидатурасын кире алу турында хәбәр иткәннәрдән кала, район Башлыгы вазифасына сайлану өчен тәкъдим ителгән барлык кандидатуралар буенча фикер алышу уздрыла. Фикер алышу вакытында кандидатлар алда торган эшчәнлек программасы белән чыгыш ясый һәм депутатларның сорауларына җавап бирә.

Һәр депутат кандидат тәкъдим иткән программа турында үзенең фикерен әйтергә, тәкъдим ителгән кандидатура яклы яки аңа каршы агитация алып барырга хокуклы.

2. Үз кандидатурасын кире алу турында хәбәр иткәннәрдән кала, район Башлыгы вазифасына сайлану өчен тәкъдим ителгән кандидатуралар буенча фикер алышканнан соң, барлык кандидатлар яшерен тавыш бирү өчен бюллетеньгә кертелә. Һәр депутат бер кандидат өчен генә тавыш бирә ала.

3. Әгәр катнашкан район Советы депутатлары санының яртысыннан артыгы аны сайлау өчен тавыш бирсә, кандидат район Башлыгы вазифасына сайланган булып санала.

4. Әгәр район Башлыгы вазифасына сайлану өчен икедән артык кандидат тәкъдим ителгән булса, һәм аларның берсе дә сайлану өчен тиешле тавыш җыя алмаса, күбрәк тавыш җыйган ике кандидат арасында икенче тур тавыш бирү үткәрелә.

5. Әгәр тавыш бирүнең икенче турында ике кандидатның берсе дә сайлану өчен тиешле тавыш җыя алмаса, район Башлыгын сайлау яңа кандидатларны тәкъдим итеп, кабат үткәрелә. Өстәвенә алдан тәкъдим ителгән кандидатларны тәкъдим итү рөхсәт ителә.

Статья 12

1. Сайланганнан соң район Башлыгы түбәндәгечә ант бирә:

“Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының миңа йөкләнгән югары бурычларын үтәгәндә Россия Федерациясе Конституциясен һәм законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, Югары Ослан муниципаль районы Уставын үтәргә, гражданнарның иминлеген тәэмин итү, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен бөтен көчемне һәм белемемне куярга ант итәм”.

Статья 13

1. Район Башлыгының вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән регламентлана.

2. Район Башлыгы - район Советы рәисенең - җәмәгать башлангычларында ярдәмчеләре булырга мөмкин.

Статья 14

1. Район Башлыгы тәкъдиме буенча район Советы тарафыннан депутатлар арасыннан район Башлыгы ярдәмчесе сайлана.

Район Башлыгы ярдәмчесе ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

2. Район Советы депутаты Район Башлыгы ярдәмчесе булып, аны сайлау өчен Район Советы депутатларының яртыдан артык өлеше тавыш биргән булса, сайланган дип санала.

3. Район Башлыгы ярдәмчесе район Башлыгы әмере белән билгеләнгән вазифаларны бүлү белән туры китергән функцияләрне, район Башлыгы йөкләмәләрен башкара. Ул вакытлыча булмаган очракта (авыру яки ялы сәбәпле) яки ул үз вазифаларын башкара алмаган очракта яки вакытыннан алда вәкаләтләре

туктатылганда, үзенең вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы район Башлыгы ярдәмчесе район Советы рәисе - район Башлыгы вазифаларын башкара.

4. Район Башлыгы ярдәмчесе вәкаләтләре гамәлдәге канун һәм район Уставында каралган нигездә вакытыннан алда туктатыла.

5. Район Башлыгы ярдәмчесе статусы белән бәйле чикләүләр федераль канун белән билгеләнгән.

6. Район Башлыгы ярдәмчесе район Башлыгы инициативасы буенча кабул ителгән район Советы карары белән яки район Советы депутатлары арасыннан өчтән бер өлешеннән ким булмаган төркемнең таләбе буенча теләсә кайсы вакытта вазифасыннан чакыртып алына ала. Район Башлыгы ярдәмчесен чакыртып алу турында карар район Советы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 4 бүлек. Район Советының даими комиссияләре

### Статья 15

1. Район Советы компетенциясенә караган мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен район Башлыгы һәм аның урынбасарыннан кала депутатлар арасыннан район Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими комиссияләр, шулай ук вакытлы комиссияләр барлыкка килә.

2. Муниципаль программалар, район Советы карарлары проектларын әзерләү өчен, район белән идарә итүгә караган әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерү өчен, район Советы каршында аның карары буенча депутатлар, район Башкарма комитеты вәкилләре, иҗтимагый оешмалар, организацияләр һәм предприятиеләр, белгечләр, экспертлар һәм район халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшләшү төркемнәре оеша ала.

### Статья 16

1. Район Советының даими комиссияләре үзләренең компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча:

1) район Советы карарлары проектлары буенча бәяләмә әзерлиләр;

2) район үсеше планнары һәм программалары проектларын, район бюджетын эшләүдә катнашалар, алар буенча үзләренең күрсәтмәләрен һәм тәкъдимнәрен кертәләр;

3) район Советы, район Башлыгы – район Советы рәисе кушуы буенча, яки үз инициативасы буенча комиссия эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы сораштыру әзерлиләр, алар буенча район Советы хокук актлары проектлары әзерлиләр;

4) үзләренең компетенцияләре кысаларында район Советы хокук актларының үтәлешен тикшереп торалар, бу сораштырулар буенча тиешле органнарның һәм җирле үзидарә органнары дәүләт хезмәтендәге шәхесләрнең докладларын һәм хисапларын тыңлыйлар;

5) район Советы утырышларында карау өчен документларның проектларын әзерлиләр;

6) район Советына яки район Башлыгына – район Советы рәисенә халык тикшерүенә урын өчен әһәмиятле булган мәсьәләләрне тикшерүгә чыгару турында яки халык алдында тыңлаулар билгеләү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәләр;

7) бу Регламент белән каралган тәртиптә район Советының чираттан тыш утырышларын чакыру турында тәкъдимнәр кертәләр;

8) район Уставы һәм әлеге Регламент белән каралган башка вәкаләтләрне тормышка ашыралар.

Статья 17

1. Район Советының даими комиссияләре комиссия рәисе һәм вәкилләре составында район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан район Советы депутатларының күпчелек тавышы белән сайлана.

2. Яңа оешкан район Советының беренче утырышында билгеләнгән район Советы даими комиссияләренең исәп составы район Советы депутатларыннан 7дән ким һәм 10нан артык булырга тиеш түгел.

3. Район Советының даими комиссияләрен сайлаган вакытта тавыш бирү тулы состав буенча үткәрелә.

4. Район Советының даими комиссияләре рәисләре альтернатив нигездә сайлана. Комиссия рәисе вазифасына кандидатуралар аның утырышларында алдан каралырга тиеш.

5. Район Советы депутаты район Советының икедән артык булмаган комиссиясендә әгъза була ала.

Статья 18

1. Район Советының даими комиссияләре рәисләре:

1) комиссия эшчәнлеген оештыруны тормышка ашыралар;

2) комиссия утырышы көн тәртибен формалаштыра һәм чакырылган шәхесләрнең исемлеген төзиләр;

3) комиссия утырышларын алып баралар;

4) комиссияне район Советының башка комиссияләре белән, район Башлыгы-район Советы рәисе белән, район территориясендә урнашкан предриятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән, массакүләм мәгълумат чаралары белән бәйләнешләрдә тәкъдим итәләр;

5) комиссия беркетмәсен имзалыйлар;

6) әлеге Регламент белән каралган башка вәкаләтләрне тормышка ашыралар.

Статья 19

1. Район Советының даими комиссияләре утырышлары, әгәр анда комиссия составының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы була.

2. Район Советының даими комиссиясе карары катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3. Район Советының берничә берләштерелгән комиссияләре утырышлырын уздырганда, карарлар һәр комиссиянең катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Статья 20

1. Район Советының даими комиссияләре үзләренең эшчәнлегенә район җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шул исәптән район Башкарма комитеты структур бүлекчәләрен, дәүләт органнарын, иҗтимагый оешмаларны, экспертларны, белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

Статья 21

1. Район Советының даими комиссияләре утырышларында аның составына кермәгән киңәш хокукы булган район Советы депутатлары катнаша ала.

Статья 22

1. Район Советы кирәк булганда вакытлы комиссияләр оештыра ала.

2. Күрсәтелгән комиссияләрнең бурычлары, вәкаләтләре һәм эшчәнлек вакытлары алар оешкан вакытта район Советы тарафыннан билгеләнә. Вакытлы комиссияләр комиссия рәисе һәм вәкилләре составында район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан район Советы депутатларының күпчелек тавышы белән оеша.

Статья 23

1. Төп мәсьәләне хәл итү өчен оешкан вакытлы комиссияләр үзләренең эшчәнлекләре нәтиҗәләре буенча район Советына доклад тәкъдим итәләр. Аерым фикерләре булган комиссия әгъзалары аны район Советы утырышында укып чыгарга хаклы. Вакытлы комиссияләрнең докладлары буенча район Советы карар кабул итә ала.

2. Вакытлы комиссияләр үзләренең эшчәнлекләрен аларга йөкләтелгән мәсьәләләрне башкарганнан соң яки район Советы карары буенча вакытыннан алда туктата ала

## 5 бүлек. Район Советының эшләү тәртибе

Статья 24

1. Яңа сайланган район Советы беренче утырышына муниципаль район составына кергән барлык җирлекләрнең депутатларын сайлаганнан соң утыз көн эчендә җыела.

2. Район Башлыгын сайлаганчы район Советының сайлаулардан соң беренче утырышын район Советының яше буенча өлкәнрәк булган депутаты алып бара.

Статья 25

1. Район Советының чираттагы утырышы кирәк булганда, ләкин кимендә өч айга бер тапкыр уздырыла.

Чираттан тыш утырышлар район Башлыгы яки район Советының билгеләнгән депутатларның кимендә өчтән бер өлеше санынча депутатлар төркеме инициативасы буенча чакырыла.

2. Әгәр район Советы утырышында сайлап куелган район Советы депутатларының 50 процентан кимерәк булмаган саны катнашса, район Советы утырышы хокуклы санала.
3. Әгәр район Советы утырышында сайлап куелган район Советы депутатларының 50 процентан кимерәге килсә, район Башлыгы әмере белән утырыш җиде көннән дә артып китмәгән башка вакытка күчерелә.
4. Район Советы депутатлары һәм чакырылган шәхесләргә чираттагы утырышны үткәрү вакыты һәм урыны турында, район Советы карауына кертеләчәк мәсьәләләр турында биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырыш турында – аны үткәрергә бер көн кала хәбәр ителә. Район Советы утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр массакүләм мәгълумат чараларында бастырып чыгарыла, яки Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтының Интернет челтәрендә урнаштырыла.

Статья 26
1. Район Советы утырышлары Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы флаглары һәм герблары урнаштырылган Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Чехов урамы, 18 йорт адресы буенча район Советы бинасының актлар залында үткәрелә.
2. Утырышлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимннарын башкару белән ачыла һәм ябыла.
3. Район Советының утырышлар залында район Башкарма комитеты, массакүләм мәгълумат чаралары вәкилләре өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар билгеләнә.

Статья 27
1. Район Советы утырышына килгән депутатларны теркәү район Советы утырышы ачылганчы бер сәгать алдан башлана.
2. Район Советы аппараты теркәүне оештыра, утырышка килгән депутатларның теркәлүе нәтиҗәләрен анализлый, һәм район Советына аның утырышында депутатларның ни сәбәпле булмауын хәбәр итә.

Статья 28
1. Район Башлыгын сайлаганнан соң Советның беренче һәм аннан соңгы утырышларын район Башлыгы - район Советы Рәисе , ә ул булмаган очракта-район Башлыгы урынбасары - район Советы Рәисе урынбасары алып бара. Әгәр Югары Ослан муниципаль районы Советы утырышында район Башлыгы - район Советы Рәисе яки аның урынбасары булмаса, район Советы үзенең составыннан вакытлыча рәислек итүче депутатны сайлый.
2. Район Советы утырышына рәислек итүче:
1) утырышны ача һәм яба;
2) депутатларга утырышка чакырылганнарның составын хәбәр итә;
3) район Советы утырышын алып бара, бу Регламентның һәм утырышның расланган эш тәртибе үтәлешен тәэмин итә;

4) җыелышның тулы хокуклы булуы өчен җитәрлек катнашучылар санын контрольдә тота;

5) докладлар һәм чыгышлар өчен сүз бирә;

6) район Советы карарлары проектларын, утырышта тикшерелгән мәсьәләләр буенча депутатларның тәкъдимнәрен тавышка куя, аларны тавышка кую тәртибен һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә;

7) аңа секретариаттан кергән депутатларның гаризалары, белешмәләре, тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләрен игълан итә;

8) утырышлар залында тәртип тәэмин итә;

9) тикшерелә торган мәсьәләләр буенча якларның хезмәттәшлеген һәм карашлары якынаюына ярдәм итә;

10) чыгышлар вакытында тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кирәк вакытта тиешле аңлатмалар биреп, төрле фикерләрне ачыклауны тәэмин итә, утырыш вакытында килеп чыккан фикер каршылыкларын бетерү максатыннан һәм башка мәсьәләләрне чишү буенча консультацияләр үткәрә;

11) кирәк булганда депутатлар белән, даими комиссияләр белән консультацияләр үткәрә, фикер каршылыкларын бетерү максатыннан вакытлы комиссияләр эшен оештыра;

12) район Советы аппараты һәм сәркатибе эшен оештыра;

13) утырыш беркетмәләрен имзалый.

3. Рәислек итүче тикшерелә торган төп мәсьәлә буенча башка депутатларга бу Регламент белән билгеләнгән вакыттан артык чыгыш ясарга хокуклы түгел, депутатларның чыгышларын, әгәр алар бу Регламентка каршы килмәсә, бүлдерергә һәм аңлатма бирергә хаклы түгел.

Статья 29

1. Район Советы утырышын үткәргән вакытка сәркатип сайлана.

Сәркатип депутатлар арасыннан ачык тавыш җирү юлы белән сайлана;

Район Советы утырышы сәркатибе:

1) утырыш беркетмәсен алып баруны оештыра;

2) сәркатипкә килгән язуларның вакытын күрсәтеп чыгыш ясаучыларны язып бара; утырышта рәислек итүчегә фикер алышуда чыгыш ясау өчен язылганнар турында мәгълуматларны җиткерә;

3) депутатларның сорауларын, белешмәләрен, хәбәрләрен, гаризаларын, тәкъдимнәрен һәм башка материалларны терки, утырышта рәислек итүчегә, комиссия редакциясенә, башка район Советы органнарына җибәрә;

4) район Советы адресына гражданнар һәм оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләр белән эшне оештыра;

5) утырышта депутатларга кирәк булган материалларны тиражлауны һәм таратуны оештыра;

6) утырыш беркетмәсендә ачык, яшерен һәм исемләп тавыш бирү нәтиҗәләрен теркәп бара;

7) утырыш барышында килеп чыккан сораулар буенча аңлатмалар бирә һәм депутатларга хәбәр итә;

8) утырыш беткәннән соң утырыш беркетмәсенә виза сала һәм рәислек итүчегә кул куярга бирә.

2. Район Советында тикшерелгән мәсьәләләр буенча депутатларның мөрәҗәгатьләрен һәм фикерләрен тулырак исәпкә алу өчен, рәислек итүче һәм башка депутатларның тәкъдимнәре буенча проект карарының тулы текстын эшләү өчен утырышта редакция комиссиясе сайлана.

Статья 30

1. Район Советының чираттагы утырышының көн тәртибе һәм эшләү тәртибе, район Советының эш планнарын һәм карарларын, шулай ук кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, район Башлыгы - район Советы рәисе тарафыннан әзерләнә һәм район Советы карауына тапшырыла. Чираттагы утырышның көн тәртибенә сораулар кертү инициативасына хокук район Уставы белән туры китереп, район Башлыгы - район Советы рәисенә, район Советы депутатларына, даими комиссияләргә, район Башкарма комитеты җитәкчесенә, хокук инициативасы булган башка субъектларга бирелә.

2. Район Советы утырышының көн тәртибе һәм эшләү тәртибе рәислек итүче тәкъдиме буенча район Советы утырышында тикшерелә һәм раслана.

3. Район Советы утырышының көн тәртибе һәм эшләү тәртибенә тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре район Советы депутатлары тарафыннан язмача рәвештә утырышның сәркатибенә, яки аларның чыгышларында аңлатылып бирелә. Язмача рәвештә кергән тәкъдимнәр утырышта рәислек итүче тарафыннан алар кергән тәртиптә игълан ителә.

4. Көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау тәртибе, алдагы мәсьәләне карауга күчү яки хәл ителмәгән алдагы мәсьәләнең берсенә әйләнеп кайту, утырышта катнашкан депутатларның күпчелек тавышы белән тормышка ашырыла.

Статья 31

1. Район Советы утырышы 10.00 сәгатьтән 18.00. сәгатькә кадәр уздырыла.

2. Утырышта доклад ясау өчен вакыт 15-30 минут кысаларында, өстәмә докладлар өчен – 5 минут, докладлар һәм карар проектлары буенча фикер алышуда катнашу өчен – 5 минут, кабат фикер алышуда катнашу өчен – 3 минут, утырышны алып бару тәртибе буенча, тавыш бирү мотивлары буенча, сораулар, тәкъдимнәр, хәбәрләр һәм белешмәләр кертү өчен чыгыш ясауга 1 минутка кадәр вакыт бирелә.

3. Катнашучы депутатларның күпчелеге ризалыгы белән яки тавыш бирүдән башка, депутатлар каршы килмәсә, рәислек итүче доклад, өстәмә доклад яки чыгышларның вакытын озынайтырга яки кыскартырга мөмкин.

Статья 32

1. Район Советы утырышы көн тәртибе мәсьәләләре буенча доклад һәм өстәмә докладтан соң, депутатларга докладчыга, өстәмә докладчыга сораулар бирү мөмкинлеге бирелә. Сораулар язма формада яки телдән бирелә. Район депутаты өчтән артык сорау бирә алмый.

2. Кирәк булса, утырышта катнашкан депутатларның күпчелек тавышы белән сорауларны туктату турында һәм доклад яки район Советының карар проекты буенча фикер алышуларга күчү турында карар кабул итә.

3. Депутат фикер алышуларда ике тапкыр гына чыгыш ясый ала. Өстәмә чыгыш ясау хокукы район Советы карары белән генә бирелә ала. Чыгыш ясау хокукын башка кешегә бирү рөхсәт ителми.

4. Фикер алышуларны туктату утырышта катнашкан депутатларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән район Советы карары буенча башкарыла. Фикер алышуларны туктату турында мәсьәләне куйганда, рәислек итүче депутатларны чыгыш ясарга язылучылар саны белән һәм аларның кайсысы чыгыш ясау турында сораганын ачыклау белән таныштыра. Әгәр депутатка фикер алышулар туктатылу сәбәпле чыгыш ясарга мөмкинлек бирелмәсә, ул үзенең чыгышы текстын сәркатипкә район Советы утырышы беркетмәсенә теркәү өчен бирә ала. Фикер алышулар тәмамланганнан соң доклад һәм өстәмә доклад ясаучы йомгаклап 5 минут чыгыш ясарга хокуклы.

Статья 33

1. Район Советы депутаты, утырышта катнашучы башка шәхес рәислек итүче аңа сүз биргәннән соң чыгыш ясый.

2. Чыгыш ясау өчен сүз гаризалар килү тәртибе буенча бирелә. Рәислек итүчегә утырышны алып бару тәртибе буенча кисәтүләрне белдерү өчен, шулай ук тавышка куйган формулировкаларны ачыклау өчен сүз чираттан тыш бирелә. Тавыш бирү мотивлары буенча, мәгълумат өчен, аңлатма бирү һәм башка процедура сораулары буенча чыгыш ясау өчен рәислек итүче тарафыннан искәрмә ясалырга мөмкин.

3. Район Советы тикшерелә торган мәсьәлә буенча чыгыш ясауларның чиратын үзгәртергә хаклы.

4. Алдан язылмыйча чиратсыз чыгыш ясау хокукына район Башлыгы-район Советы рәисе, район Башкарма комитеты рәисе, утырышта рәислек итүче ия.

Статья 34

1. Район Советы утырышында район Советы депутаты, аның буенча сүз алган көн тәртибе мәсьәләсенең асылы буенча чыгыш ясарга бурычлы. Район Советы депутатларының чыгышларына аңлатма бирергә, чыгыш ясаучыларга тасвирлама бирергә беркем дә хаклы түгел.

2. Район Советы утырышында чыгыш ясаучы тупас һәм корректлы булмаган әйтелмәләргә һәм гамәлләргә юл куймаска, законсыз һәм мәҗбүри гамәлләргә өндәргә тиеш түгел. Бу таләпләрне бозган очракта рәислек итүче мондый әйтемнәр, өндәүләрнең һәм гамәлләрнең ярамауы турында рәсми рәвештә кисәтү ясый.

3. Кабат бу таләпләрне бозган очракта рәислек итүче депутатның чыгышын туктата. Әлеге депутатка шулай ук утырышта катнашкан депутатларның күпчелек тавышы белән район Советы карары буенча утырыш буе сүз бирелми.

4. Әгәр чыгыш ясаучы тикшерелә торган темадан читләшсә, рәислек итүче аны тикшерелә торган темага якын торырга чакыра.

Статья 35

1. Утырышта катнашучы һәм район Советы депутаты булмаган шәхес тәртип бозган очракта, рәислек итүче әмере буенча утырышлар залыннан чыгарыла.

Статья 36

1. Район Советының һәрбер утырышында беркетмә алып барыла. Техник мөмкинлекләр булган очракта, фонограмма һәм стенграмма алып барыла.

2. Утырыш беркетмәсендә күрсәтелә:

1) район Советы утырышының датасы һәм үткәрү урыны һәм тәртип номеры;

2) депутатларның билгеләнгән саны, аларның фамилияләрен, исемнәрен, әтисенең исемен күрсәтеп утырышта катнашучы депутатларның саны;

3) рәилек итүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы;

4) район Советы утырышның көн тәртибендәге мәсьәләләр, доклад һәм өстәмә доклад ясаучыларның һәм район Советы карауына куелган һәр мәсьәлә буенча барлык чыгыш ясаучыларның фамилияләре, инициаллары, вазифалары;

5) тавыш бирү өчен барлык тәкъдимнәрнең формулировкасы һәм “әйе”, “каршы” яки тыелып калган дип тавыш биргән барлык депутатларның санын күрсәтеп тавыш бирүләрнең нәтиҗәләре, ә тавыш бирүне исемнәрен әйтеп үткәргәндә – шулай ук депутатларның фамилияләре һәм инициаллары.

3. Беркетмәгә карар проектлары һәм бергә материаллар, текстлар яки чыгышларның хикәяләүләре һәм утырыш барышында депутатлар һәм чыгыш ясаучылар тарафыннан сәркатипкә бирелгән башка материаллар, район Советы кабул иткән актларның тулы текстлары теркәлә.

4. Район Советы утырышы беркетмәсе район Советы утырышы тәмамланганнан соң биш көн эчендә рәсмиләштерелә, сәркатип тарафыннан виза салына һәм район Башлыгы - район Советы рәисе тарафыннан имзалана.

5. Беркетмә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә. Беренчесе билгеләнгән тәртиптә архивка тапшырыла. Беркетмәнең икенче нөсхәсе район Советы Аппаратында саклана һәм район Советы депутатлары һәм район халкының үтенече буенча танышу өчен бирелә.

6 бүлек. Тавыш бирү һәм карарлар кабул итү тәртибе

Статья 37

1. Район Советы карарлары кагыйдә буларак, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

2. Канун белән, район Уставы белән һәм әлеге Регламент белән билгеләнгән очракларда, шулай ук район Советы карары буенча яшерен тавыш бирү үткәрелә.

3. Район Советы карары белән аерым мәсьәләләр буенча исемнәрен атап тавыш бирү үткәрелә ала.

Статья 38

1. Ачык тавыш бирү үткәрелгәндә тавышларны утырышның сәркатибе саный.

2. Тавыш бирү башланыр алдыннан рәислек итүче тавышка куелучы тәкъдимнәр саны турында хәбәр итә, аларның формулировкасын һәм тавышка нинди тәртиптә куелуын ачыклый, карар ничә тавыш белән кабул ителергә тиеш икәнен искәртә.

3. Бер яки ике тәкъдим буенча тавыш биргәндә, һәр депутат бер тапкыр “әйе”, “каршы” яки тыелып калган дип тавыш бирегә хокуклы. Әлеге Регламент буенча аның өчен тиешле депутатлар санынча тавыш бирелгән булса, тәкъдим кабул ителгән булып санала.

4. Әгәр тавыш бирүгә бер мәсьәлә буенча икедән артык тәкъдим кертелсә, һәр депутат үзенең тавышын тәкъдимнең һәрберсенә “әйе”, “каршы” дип бирә, шулай ук теләсә кайсы тәкъдим өчен (рейтинглы тавыш бирү) тавыш бирүдән тыелып калырга хокуклы. Иң күп тавыш җыйган ике тәкъдим, әлеге маддәнең өченче өлешендә каралган тәртиптә кабаттан тавышка куела. Әгәр бу очракта да тәкъдимнәрнең берсе дә бу Регламент буенча карар кабул итү өчен тиешле тавышны җыя алмаса, рәислек итүче тәкъдиме буенча яңа карар проектын эшләү өчен депутат килешү комиссиясе формалаша.

5. Тавыш бирү тәмамланганнан соң утырышта рәислек итүче аның нәтиҗәләрен игълан итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре район Советы утырышының беркетмәсенә кертелә.

Статья 39

1. Яшерен тавыш бирүне үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен район Советы депутатлар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән санау комиссиясен сайлый. Санау комиссиясенә сайлау органнары составына яки сайлап куелган вазифага тәкъдим ителгән депутатлар керә алмый.

2. Санау комиссиясе үзенең составыннан комиссия рәисен һәм сәркатипне сайлап куя, шул турыда беркетмә төзелә.

3. Комиссия карарлары аның әгъзаларының күпчелек тавыш бирүе белән кабул ителә һәм комиссия рәисе һәм сәркатибе имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4. Яшерен тавыш бирү өчен бюллетеннәр санау комиссиясе контрольлегендә ул билгеләгән формада һәм тиешле күләмдә әзерләнә. Бюллетеннәрдә тавыш бирү өчен кирәкле мәгълуматлар булырга тиеш. Сайлау бюллетеннәрендә карар проектлары буенча яки сайлап куелган вазифага бердәнбер кандидатура булганда “әйе”һәм “каршы” сүзләре торырга тиеш.

5. Тавыш бирүне үткәрү вакыты һәм урыны, аны үткәрү тәртибе бу Регламент нигезендә санау комиссиясе тарафыннан билгеләнә, һәм комиссия рәисе тарафыннан игълан ителә.

6. Тавыш бирүне үткәрү өчен комиссия утырышта катнашкан һәр депутатка тавыш бирү өчен бер бюллетень бирә.

7. Бюллетенне тутыру бюллетендәге депутат каршы тавыш биргән кандидат фамилиясен, ә карар проекты буенча (карар варианты буенча) бюллетендә яки бер кандидатура белән - тәкъдим ителгән карарлар варианты яки кандидат фамилиясе янына “әйе” яки “каршы” сүзләрен сызу юлы белән башкарыла. “Әйе” һәм “каршы”

сүзләрен икесен дә, яки бөтен кандидатларның фамилияләрен сызу, шулай ук бюллетенне тутырмау тавыш бирүдән тыелган булып санала.

8. Тавыш бирү бюллетене тавыш бирү кабинасында тутырыла һәм тавыш бирү өчен печатьләп куйган урнага салына.

9. Санау комиссиясе тавыш бирү тәмамланганнан соң урнаны ача, дөрес һәм дөрес булмаган бюллетеннәрнең санын билгели һәм тәкъдим өчен бирелгән каршы һәм каршы булмаган тавышларны санауны башкара. Тавышларны санаган вакытта район Советы депутатлары катнаша ала.

10. Билгеләнмәгән формадагы бюллетеньнәр, ә вазыйфаи затны сайлаганда бер вазыйфага ике яки аннан күбрәк кандидатның фамилияләре калган бюллетеньнәр дөрес түгел дип санала.

11. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында санау комиссиясе санау комиссиясенең барлык әгъзалары имзалаган һәм район Советы утырышында укылган беркетмә төзи.

Статья 40

1. Исемнәрен атап тавыш бирү район Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән береннән ким булмаган саны таләбе буенча үткәрелә.

2. Исемнәрен атап тавыш бирүне үткәрү өчен һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен район Советы депутатлар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән сайлау комиссиясен сайлый.

3. Район Советы утырышында яшерен дә һәм исемнәрен атап та тавыш бирү үткәрелгән очракта, район Советы аны оештыруны санау комиссиясенең бер составына тапшыра ала.

Исемнәрен атап тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелү өчен сәркатипкә тапшырыла һәм район Советы утырышында игълан ителә, шулай ук массакүләм мәгълумат чараларыннда бастырылып чыгарыла, яки Интернет челтәрендә районның рәсми сайтында урнаштырыла.

Статья 41

1. Бер үк мәсьәлә буенча кабаттан тавыш бирү бу мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен кирәк булган шундый ук күпчелек тавыш бирү юлы белән район Советы карары буенча рөхсәт ителә. Тавышларны санау вакытында хата киткән булса, тавыш бирүгә куелган мәсьәләдә ачыклык булмаса, әлеге Регламентны бозган башка очраклар булса моның өчен җирлек булып тора.

Статья 42

1. Процедура мәсьәләләре буенча карарлар район Советы утырышында катнашкан депутатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсендә чагыла.

2. Процедурага түбәндәге мәсьәләләр керә:

1) район Советы утырышы сәркатибен сайлау турында;

2) утырышның көн тәртибен раслау турында;

3) утырышның көн тәртибе проектына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

4) утырышның көн тәртибен яңа мәсьәлә белән тылыландыру турында;
5) утырышны берничә этапта үткәрү турында;
6) утырышта тәнәфес турында, утырышны күчерү һәм ябу турында;
7) чыгыш ясау өчен өстәмә вакыт бирелү турында;
8) утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча чыгыш ясауларны күчерү яки туктату турында;
9) утырышның көн тәртибе мәсьәләләренә күчү (кайту) турында;
10) район Советының тиешле даими комиссиясенә мәсьәләне карауны тапшыру;
11) фикер алышудан башка тавыш бирү;
12) хокук актлары проектларына төзәтмәләр кертүне кабул итү яки кире кагу;
13) ябык утырыш үткәрү турында;
14) утырышта рәислек итүченең функцияләрен тапшыру;
15) район Советы утырышында карала торган карар проектлары һәм башка мәсьәләләр буенча тиешле мәгълуматларны һәм нәтиҗәләрне бирү өчен утырышка шәхесләрне чакыру;
16) утырышта катнашучыларга бирелә торган мәгълуматларны, белешәләрне исәпкә алу турында;
17) тавыш бирүне үткәрү тәртибен үзгәртү турында;
18) өстәмә теркәү уздыру турында;
19) тавышларны кабат санау турында;
20) район Советы утырышын үткәрү вакытын озынайту турында;
21) утырышка депутатның (депутатларның) мөрәҗәгатьләрендә булган сорауларга җавап бирү өчен дәүләт хезмәтендәге шәхесне чакыру турында;
22) район Башкарма комитетының үзенең эшчәнлеге турында чираттан тыш отчёт тапшыруы турында;
23) әлеге Регламент белән туры китереп район Советы утырышында катнашан депутатларның күпчелек тавыш бирүе белән кабул ителгән мәсьәләләр буенча башка сораулар.

## 7 бүлек. Район Советының хокук актлары

Статья 43

1. Район Советы, үзенең компетенциясе кысаларында, Федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары һәм район Уставы белән билгеләнгән тәртиптә норматив һәм башка хокук актлары кабул итә.

2. Район Советының норматив хокук актлары, шулай ук норматив булмаган хокук актлары карарлар формасында кабул ителә.

3. Район Советы хокук актлары көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә кысаларында кабул ителә.

4. Район Советы хокук актларына район Башлыгы – район Советы рәисе, район Уставында билгеләнгән тәртиптә, аларны кабул иткәннән соң һәм халыкка җиткерелгәч, өч көн эчендә кул куя.

## 8 бүлек. Район Советының муниципаль норматив хокук актларын кабул итү тәртибе

Статья 44

1. Муниципаль хокук актлары проектлары район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район Прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шулай ук аларның карамагында булган мәсьәләләр буенча районның Контроль-хисап Палатасы, районның Финанс-бюджет Палатасы, районның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан кертелә ала.

2. Район Советына муниципаль хокук акты проектын керткән вакытта булырга тиеш:

1) муниципаль хокук акты проектының тексты;

2) аңлатма язуы;

3) белешмә материаллар (булган очракта) (кертелгән мәсьәлә буенча мәгълумат, иллюстрация материалы, схемалар, таблицалар һ.б.);

4) финанс- икътисад нигезе ( бу проектны тормышка ашыру матди чыгымнар таләп иткән очракта);

5) Контроль-хисап Палатасы нәтиҗәсе (карар проекты муниципаль финанс контроле предметы булган мәсьәләләргә кагылган очракта);

6) бюджет канунында каралган документлар һәм материаллар (район бюджеты һәм район бюджеты үтәлеше турында карар проектлары буенча);

7) чагыштыру таблицасы (район Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын керткән очракта);

8) әлеге мәсьәлә буенча докладчылар, чыгыш ясаучылар һәм чакырылганнар исемлеге;

9) әлеге муниципаль хокук акты проектын кабул итү сәбәпле кабул ителергә, үзгәртелергә, көчен югалткан дип санарга яки туктатылырга тиешле муниципаль хокук актлары исемлеге (кирәк булганда).

3. Башкарма комитет җитәкчесе, башка җирле үзидарә органнарының җитәкчеләре тарафыннан кертелгән муниципаль хокук актларына Башкарма комитетта, башка җирле үзидарә органнарына ярашлы итеп билгеләнгән тәртиптә виза салынырга тиеш. Бергә теркәлгән материалларда башкаручының, шулай ук проектны эшләүче бүлекчә җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы һәм эш телефоны булырга тиеш.

4. Барлык муниципаль норматив хокук актлары проектлары коррупция факторларын ачыклар өчен экспертиза (коррупциягә каршы экспертиза) үтәргә тиеш.

5. Коррупциягә каршы экспертиза норматив хокук актларын һәм норматив хокук актлары проектларына Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе белән туры китереп коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы булган дәүләт хезмәтендәге шәхес тарафыннан үткәрелә.

6. Барлык муниципаль норматив хокук актлары проектлары норматив хокук актларын һәм норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Интернет челтәрендә районның рәсми сайтында урнаштырыла.

7. Барлык муниципаль норматив хокук актлары гамәлдәге кануннарга туры килүен өйрәнү өчен район прокуратурасына җибәрелә.

8. Җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм бетерүне, җирле бюджеттан тотылган чыгымнарны тормышка ашыруны күздә тоткан район Советы карарлары проектлары район Советы карауына район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча яки аның бәяләмәсе булганда кертелә ала. Күрсәтелгән бәяләмә район Советына муниципаль норматив хокук акты проектын район Башкарма комитетына тәкъдим иткәннән соң утыз көн эчендә тәкъдим ителә.

9. Муниципаль норматив хокук акты проекты һәм аңа беркетелгән материаллар язмача формада район Башлыгы – район Советы рәисе исеменә җибәрелә.

Статья 45

1. Килгән муниципаль норматив хокук акты проекты һәм аңа беркетелгән материаллар район Советы аппараты тарафыннан кергән көнне теркәлә.

2. Район Башлыгы – район Советы рәисе муниципаль норматив хокук акты проектын һәм аңа беркетелгән материалларны теркәгәннән соң бер тәүлек эчендә тәкъдим ителгән мәсьәлә алар карамагында булган район Советының даими комиссиясенә җибәрә. Тиешле актның проекты башта коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы булган дәүләт хезмәтендәге шәхескә җибәрелә, һәм шулай ук район прокуратурасына җибәрелә, уңай бәяләмә алганнан соң аңа теркәлгән барлык материаллар белән бергә район Советының даими комиссиясенә җибәрелә.

3. Әгәр тапшырылган муниципаль норматив хокук акты әлеге Регламент таләпләренә туры килмәсә, яки бу Регламентның 45 статьясендә күрсәтелгән аның буенча кирәкле материаллар тапшырылмаган булса, мондый проект район Башлыгы-район Советы Рәисе тарафыннан инициаторга әлеге Регламент белән билгеләнгән таләпләр белән туры китереп үтәү өчен кире кайтарыла.

4. Муниципаль норматив хокук акты проекты буенча аны район Советы караганга кадәр район Уставында һәм район Советының норматив хокук актларында билгеләнгән тәртиптә халык алдында тыңлаулар билгеләнергә мөмкин.

Статья 46

1. Муниципаль норматив хокук акты проектын карау тәртибе, даими комиссиядә проект буенча бәяләмә әзерләү әлеге Регламент нигезендә мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

2. Проектлар өстендә эшләү өчен даими комиссия аның эшендә проектның инициаторы яки аның вәкиле катнашырга хокуклы булган эшче төркемнәр оештыра ала.

3. Альтернатив муниципаль норматив хокук акты проектлары даими комиссия тарафыннан төп проект белән бер үк вакытта карала.

4. Даими комиссиядә муниципаль хокукый акт проекты буенча фикер алышу, проектны керткән хокук чыгару инициативасы субъекты вәкилен чакырып, ачыктан-ачык уза.

5. Аның эшендә катнашмаган комиссия әгъзасы даими комиссиягә каралырга тиешле үзенең тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен җибәрергә хаклы. Тәкъдимнәрне һәм күрсәтмәләрне карап чыгу нәтиҗәләре турында даими комиссия рәисе телдән район Советы утырышына шундый тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр җибәргән район Советы депутатларын таныштыра, шулай ук утырышта аны карарга әзер булуы турында хәбәр итә.

Статья 47

1. Тикшерелә торган проект аның карамагында булган район Советы даими комиссиясенә проектка төзәтмәләр язма формада проектның аерым кагыйдәнамәләренең редакциясен үзгәртеп, яки проектка конкрет сүзләр, пунктлар, өлешләр, статьялар һәм башка кагыйдәнамәләр белән өстәмәләр кертеп, яки проектның конкрет кагыйдәнамәләрен төшереп калдыру турында тәкъдимнәр белән хокукиҗат инициативасы субъектлары тарафыннан кертелә.

2. Проектка төзәтмәләр район Советының даими комиссиясе утырышында каралырга тиеш, утырышның вакыты турында проектны тәкъдим иткән хокукиҗат инициативасы субъектлары, шулай ук карала торган проектка төзәтмәләр керткән хокук чыгару инициативасы субъектларына хәбәр ителә. Төзәтмәләр таблицасы күрсәтелгән шәхес тарафыннан аны даими комиссиядә караганга кадәр бер атнадан соңга калмыйча алдан ук җибәрелә.

3. Төзәтмәләрне карап тикшергән вакытта фикер алышу тавышы хокукы булган хокук чыгару инициативасы субъектлары, яки аларның вәкилләре катнашырга хокуклы. Төзәтмәләр керткән хокук чыгару инициативасы субъекты, яки аның вәкиле кертелгән төзәтмәләрнең редакциясен аларны тикшергән вакытта дәлилләргә һәм ачыкларга, яки карап чыгудан төшереп калдырырга хокуклы.

4. Тикшерү нәтиҗәләре буенча даими комиссия төзәтмәләр белән ризалаша ала һәм аны муниципаль норматив хокук акты проекты текстына кертергә, яки кире кагырга тәкъдим итә ала.

5. Муниципаль хокук акты проекты даими комиссиядә каралганнан соң район Башлыгына – район Советы рәисенә район Советының якындагы утырышының көн тәртибенә кертү өчен җибәрелә.

Статья 48

1. Гражданнарның хокук чыгару инициативасын тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокук акты проекты район Советының ачык утырышында аны керткән көннән соң өч ай эчендә һичшиксез карап чыгарылырга тиеш.

2. Муниципаль хокук акты проектын керткән гражданнарның инициатив төркеме вәкиленә (вәкилләренә) алар керткән муниципаль хокук акты проектын карап тикшерү вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә, алар бу проектны тикшергәндә район Советы утырышында катнашырга һәм үзләренең карашларын аңлатып бирергә хокуклы.

3. Муниципаль хокук акты проектын тикшергән вакытта гражданнарның инициатив төркеме вәкиле (вәкилләре) булмаса, проектны карап чыгу район Советының башка утырышына күчерелә. Муниципаль хокук акты проектын кабат тикшергән вакытта гражданнарның инициатив төркеме вәкиле (вәкилләре) булмаса, тиешле проект район Советы тарафыннан әлеге шәхесләр катнашыннан башка гына карала.

4. Муниципаль хокук акты проектын карап чыгу нәтиҗәләре буенча кабул ителгән дәлилләнгән карар язма формада гражданнарның инициатив төркеме вәкиленә (вәкилләренә) җиде көн эчендә җиткерелә.

Статья 49

1. Район Советында хокук актлары проектларын карап чыгу канун белән, район Уставы белән, район Советы белән конкрет проектка җайлаштырылган башка нәрсә билгеләнмәгән булса, беренче укылышта тормышка ашырыла.

2. Район Советының муниципаль хокук актлары проектлары түбәндәге эзлекле

тәртиптә кабул ителә:

1) проектны тикшерү;
2) проектны нигез итеп алу;
3) төзәтмәләр кертү;
4) хокук актын тулысынча кабул итү.

Статья 50

1. Район Советы утырышында муниципаль хокук акты проектын карап чыгу хокук чыгару инициативасы субъектының, яки аның вәкиленең докладыннан башлана.

2. Докладчы шулай ук даиими комиссиядә проектны карап чыгу нәтиҗәләре турында, кергән тезәтмәләр турында, аларны карап чыгу йомгаклары һәм нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

3. Докладтан соң район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, экспертлар һәм фикер алышуда катнашуга чакырылган башка шәхесләрнең тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре тыңланыла.

4. Рәислек итүче район Советы утырышында катнашучы район Советы депутатларының яки хокук чыгару инициативасы субъектының яки аларның вәкилләренең муниципаль хокук акты проектына төзәтмәләре барлыгын ачыклый. Әгәр төзәтмәләр булмаса, рәислек итүче муниципаль хокук акты проектын тулаем кабул итү турында мәсьәләне тавыш бирүгә куя. Әгәр муниципаль хокук акты проектына төзәтмәләр булса, рәислек итүче төзәтмәләрне кабул итү турында мәсьәләне тавыш бирүгә куя. Төзәтмәләрнең авторы, даими комиссиянең рәисе, шулай ук район Советы депутаты яки хокук чыгару инициативасының башка субъекты яки аның вәкиле каршы килсә, үзләренең позицияләрен чыгышларында дәлилли ала.

Төзәтмәләрне (төзәтмәне) кабул итү турында карар катнашучы район Советы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Әгәр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча мондый тәкъдим тиешле тавыш җыя алмаса, төзәтмә өстәмә тавыш бирдән башка кире кагылган булып санала.

5. Төзәтмәләр буенча тавыш бирү тәмамлангач, рәислек итүче муниципаль хокук акты проектын тулаем кабул итү турында тәкъдимне тавышка куя. Район Советының муниципаль хокук акты проекты аның өчен район Советы депутатлары арасыннан күпчелек тавыш бирелсә, кабул ителгән булып санала.

6. Әгәр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча проектны тулаем кабул итү турындагы тәкъдим җитәрлек тавыш җыя алмаса, бу проект даими комиссиягә эшләп бетерү өчен кире кайтарыла, яки район Советы проектны кире кагу турында карар кабул итә ала. Проектны эшләп бетерү өчен кире кайтарганда, район Советы утырышында кабул ителгән төзәтмәләрне исәпкә алып район Советы әлеге проектка өстәмә төзәтмәләр кертү срогын билгели.

7. Район Советы карары буенча кирәк очракта утырышта катнашучы депутатлар арасыннан күпчелек тавыш бирү юлы белән муниципаль хокук акты проектын тулаем кабул итү турында тавыш бирү кичектерелә ала, ә проект эчке юридик каршылыкларны бетерү өчен, проект кагыйдәнамәләре һәм лингвистик таләпләрнең дөрес бәйләнешен булдырыр өчен район Советы билгеләгән срокларда район Советының юридик бүлегенә җибәрелә.

8. Район Советы тарафыннан муниципаль хокук акты проектын тулаем кабул иткәннән соң аның текстына ниндидер үзгәрешләр, шул исәптән карарның мәгънәсен һәм эчтәлеген үзгәртә торган редакцияләүләр рөхсәт ителми.

Статья 51

1. Район Советы тарафыннан район бюджеты турында карар проектын карау һәм раслау тәртибе, аның үтәлеше турында отчёт район Советы норматив хокук акты белән билгеләнә.

9 бүлек. Район Уставы проектын карап тикшерү үзенчәлекләре, район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарлар

Статья 52

1. Район Уставы проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты район Советына район Башлыгы, район Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре тарафыннан кертелә ала.

2. Район Уставы проектын, район Уставына үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проектын карау район Советы утырышларында әлеге Регламент белән каралган тәртиптә икедән дә ким булмаган укылышта тормышка ашырыла.

3. Район Уставы проектын, район Уставына үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проектын әзерләү өчен махсус комиссия төзелә ала. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарының белгечләре, экспертлар чакырыла ала.

4. Район Уставы, район Уставына үзгәрешләр кертү турында карар район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икедән күбрәк тавыш белән кабул ителә.

Статья 53

1. Район Уставы проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проекты район Советы аларны карап чыкканнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълумат чараларында рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш, яки Татарстан Республикасының хокук мәгълумат рәсми сайтында һәм районның рәсми сайтында Интернет мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Статья 54

1. Район Уставы проекты буенча, Уставка үзгәрешләр бары тик Уставта беркетелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә һәм федераль законнарга туры китерү максатларында гына кертелә торган очраклардан тыш, район Советының район Уставына үзгәрешләр кертү турындагы карарларын район Советы утырышына карау алдыннан гавами тыңлаулар уздырыла.

Статья 55

1. Устав проектларына һәм район Уставына үзгәрешләр кертү турында район Советы карарына төзәтмәләр һәрберсе аерым тикшерелә һәм алар өчен тавыш бирелә. Төзәтмә район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икедән ким булмаган күпчелек тавыш белән кабул ителә.

2. Район Уставы проектын яки район Уставына үзгәрешләр кертү турында карар проектын тикшергәннән соң һәм булган юридик каршылыкларны бетергәннән соң район Уставы проекты, Уставка үзгәрешләр кертү турында район Советы карары проектын кабул итү турындагы карар район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икедән ким булмаган күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 10 бүлек. Район Советы тарафыннан башка карарлар кабул итү тәртибе

Статья 56

1. Район Советы район Советы карарлары формасында рәсмиләштерелә торган норматив булмаган характердагы актларны түбәндәге мәсьәләләр буенча кабул итә:

1) район Башлыгын – район Советы рәисен сайлау, отставкасын кабул итү турында;

2) район Башлыгы ярдәмчесен – район Рәисе ярдәмчесен сайлау һәм вазифасыннан азат итү турында;

3) район Советының даими комиссияләрен формалаштыру, аларның рәисләрен сайлау һәм аларны вазифаларыннан азат итү турында;

4) районның Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү турында;

5) район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору, җирле референдум үткәрү турында инициативаны күрсәтү турында;

6) район чикләрен үзгәртү, районны үзгәртеп кору, җирле референдум билгеләү мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү турында;

7) район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына конкурс билгеләү турында;

8) район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын (алда-конкурс комиссиясе) билгеләү турында;

9) районның сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында, Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының башка дәүләт хезмәтендәге шәхесләрен билгеләү (сайлау, килештәрү) турында;

10) халык алдында тыңлаулар турында;

11) гражданнарны сораштыру үткәрү;

12) муниципаль хокук актлары проектларын һәм башка әһәмиятле булган мәсьәләләрне халык тикшерүенә кертү;

13) район Советының үз-үзен таркату турында, район Советы депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуы турында;

14) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгара торган инициатива турында;

15) Татарстан Республикасы Конституцион судына мөрәҗәгать турында;

16) прокурорның (вәкилнең) каршы килүне карау турында;

17) район Советы карамагында булган башка мәсьәләләр (процедурадан кала) буенча.

2. Күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карар канун белән, район Уставы белән башка нәрсә каралмаган булса, район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш бирсә, кабул ителгән булып санала.

Статья 57

1. Бу Регламентның 56 статьясында күрсәтелгән мәсьәләләрне район Советы карап тикшерүенә кертү инициативасы канун белән, район Уставы белән, әлеге Регламент белән билгеләнгән хокук чыгару инициативасы субъектларына, башка шәхесләргә, органнарга, оешмаларга карый.

2. Күрсәтелгән мәсьәләләрне район Советы карап тикшерүенә кертү инициаторы район Советына карар проектын тапшыра, шулай ук канун белән, район Уставы белән, әлеге Регламент белән каралган һәм бу мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра.

3. Район Советы тарафыннан кадрлар мәсьәләсен чишкән вакытта шулай ук

һәр кандидатка объектив белешмә бирелергә тиеш, кандидатның әлеге вазифаны башкару өчен билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаучы документлар һәм бу вазифаны башкарырга киртә булган чикләүләрнең булмауы турында документлар тапшырылырга тиеш.

Статья 58

1. Бу Регламентның 56 статьясында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карар район Советы тарафыннан, канун белән, район Уставы белән, әлеге Регламент белән карарны кабул итү өчен башка вакыт билгеләнмәгән булса, ул район Советына кертелгәннән соң бер ай эчендә кабул ителә.

2. Күрсәтелгән мәсьәләләр, каралырга тәкъдим ителгән мәсьәләне карап чыгу аларга караган район Советының даими комиссияләре алдан карап чыкканнан соң, район Советы тарафыннан карала.

3. Күрсәтелгән мәсьәләләр буенча кергән материалларны теркәү, аларны алдан карап чыгу район Советы муниципаль хокук актлары проектларын карап чыгу һәм теркәү өчен әлеге Регламент белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча тормышка ашырыла.

Статья 59

1. Район Советының кадрлар мәсьәләләре буенча карарларыннан кала норматив характерда булмаган карарлары проектлары, җирле референдумны билгеләү, аларны район Советында карап чыкканчы халык алдында тыңлауларга яки халык тикшерүенә чыгарыла алалар. Районны үзгәртеп кору турында инициативаны тәкъдим итү турында карар проекты мәҗбүри рәвештә халык тыңлауларына чыгарыла.

11 бүлек. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү

Статья 60

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе район Советы тарафыннан әлеге вазифага конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан билгеләнә.

Статья 61

1. Район Башкарма комитетыҗ вазифасын башкаручыга конкурсның нәтиҗәләре турында мәгълумат белән конкурс комиссиясе рәисе чыгыш ясый.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына һәр кандидат район Советы утырышында үзенең вәкаләтләре вакытына эшчәнлегенең кыскача программасы белән чыгыш ясый.

3. Район Советы депутатлары конкурс комиссиясе рәисенә, кандидатларга сораулар бирергә хокуклы, күрсәтелгән кандидатларны яклап яки каршы агитация алып барырга хокуклы.

Статья 62

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турында мәсьәлә район Советы тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән хәл ителә.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесен билгеләү турындагы карар, әгәр аның өчен катнашучы район Советы депутатларының күпчелек өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

Статья 63

1. Әгәр конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан берсе дә район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына билгеләү өчен депутатларның тиешле тавыш санын җыя алмаса, район Советы район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына кабаттан конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

2. Бу карарны кабул итү белән беррәттән район Советы район Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына шул составтагы конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс үткәрү турында, яки конкурс комиссиясенең яңа составын формалаштыру турында карар кабул итә. Район Советы конкурс комиссиясенең сан ягыннан составын үзгәртү турында карар кабул итә ала

12 бүлек. Районның Контроль- хисап Палатасы рәисен сайлау һәм азат итү турында

Статья 64

1. Район Уставына туры китереп бюджет үтәлешенә контроль һәм район Советының муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм куллануны билгеләнгән тәртибен саклау өчен Контроль - хисап Палатасы рәисе составында районның Контроль - хисап Палатасын оештыра.

2. Контроль - хисап Палатасы рәисе вазифасына район Башлыгы тәкъдиме белән район Советы тарафыннан билгеләнә.

3. Контроль- хисап Палатасы рәисе вазифасына сайлау һәм аны вазифасыннан азат итү катнашучы район Советы депутатларының күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

13 бүлек. Районның сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү һәм вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

Статья 65

1. Районның Сайлау комиссиясе районның җирле үзидарә органнары структурасына кермәгән муниципаль органы булып тора.

2. Районның Сайлау комиссиясе федераль канун, Татарстан Республикасы кануны һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокта формалаша.

3. Районның Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү Россия Федерациясе бюджеты чыгымнары классификациясе белән туры китереп район бюджетында аерым юл белән каралган.

4. Районның Сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантиеләре федераль канун, Татарстан Республикасы кануны һәм әлеге Устав белән җайга салына.

14 бүлек. Районның Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасына кандидатларны карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү тәртибе

Статья 66

1. Конкурс комиссиясе әгъзалары район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураны карау өчен "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы һәм "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә билгеләнә.

Статья 67

1. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санын билгеләү турында район Советы карары Югары Ослан муниципаль районы депутатларының катнашучылар санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

2. Район Советы тарафыннан билгеләнгән конкурс комиссиясе составына кандидатлар район Башлыгы тарафыннан тәкъдим ителә.

3. Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысын билгеләү турында район Советы карары район Советы депутатларының катнашучылар санының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында тавыш бирү һәр кандидатура буенча аерым тормышка ашырыла.

4. Конкурс комиссиясе әгъзаларының билгеләү район Советының бер карары белән рәсмиләштерелә.

15 бүлек. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында район Советының законнар чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру

Статья 68

1. Район Советы Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы белән туры китереп Татарстан Республикасы Дәүләт Советында законнар чыгару инициативасы хокукына ия.

Статья 69

1. Район Советының законнар чыгару инициативасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән таләпләр белән туры китереп рәсмиләштерелә.

Статья 70

1. Закон проектын законнар чыгару инициативасы хокукын тормышка ашыру тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү турында карар район Советы депутатларының катнашучылар санының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм тиешле карар белән рәсмиләштерелә.

2. Район Советы карарында район Советы комитетларда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында аны карап тикшергән вакытта закон проектын тәкъдим итүне тапшырган шәхес күрсәтелә.

3. Әзерләнгән закон проекты кирәкле материаллар һәм район Советы карары белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.

16 бүлек. Район Советының контроль функцияләрне тормышка ашыруы

Статья 71

1. Район Советы район территориясендә бу Уставның кагыйдәнамәләре үтәлешен, район Советы кабул иткән норматив актлар, район бюджеты үтәлешен, бюджеттан тыш акчаларны куллану, районның үсеш программаларын, район Башкарма комитеты һәм аның җитәкчесенең эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыра.

2. Район җирле үзидарә органнары һәм аларның вазифаи затлары кануннарны, бу Уставны һәм башка муниципль хокук актларын бозган очракта, билгеләнгән фактларны тикшерү өчен депутатларының катнашучылар санының күпчелек тавышы белән кабул ителгән район Советы карары нигезендә депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләр оешырга мөмкин.

Статья 72

1. Район Советының һәрбер карарында, кагыйдә буларак аның үтәлешен контрольдә тоту йөкләнгән даими комиссия яки район Советы депутаты күрсәтелә.

2. Контрольнең максаты булып хокук актының нәтиҗәлелек дәрәҗәсен, аның үтәлүенә комачаулаучы сәбәпләрен, үтәлүгә каршы булган шәхесләрне билгеләү, аларны җаваплылыкка тарту, шулай ук кирәк булганда судта яклауны билгеләү тора.

3. Карарның һәрбер контроль пунктында үтәүче, һәм кагыйдә буларак, үтәлү вакыты күрсәтелә. Аларга контроль йөкләнгән даими комиссия яки депутат хокук акты үтәлешенең барышы турында вакытында хәбәр әзерләргә тиеш.

4. Мондый хәбәрне тыңлаганнан соң район Советы хокуклы:

1) хокук актын үтәлгән итеп контрольдән алырга;

2) контроль вәкаләтләрне озынайтырга;

3) контроль вәкаләтләрне башка комиссиягә яки депутатка тапшырырга;

4) хокук актын гамәлдән чыгарырга;

5) хокук актын үзгәртергә яки тулыландарырга.

5. Контроль буенча хисап вакыты хокук актының үзендә яки беркетмә карарында билгеләнә.

Статья 73

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе елга бер тапкыр район Башлыгы – район Советы рәисе сорауы буенча үзенең һәм район Башкарма комитетының эшчәнлеге турында хисап тапшыра.

2. Район Советы утырышында хисап белән район Башкарма комитеты җитәкчесе яки аның урынбасары чыгыш ясый.

3. Район Башкарма комитеты эшчәнлеге турында хисапны тикшерү нәтиҗәләре буенча район Советы карар кабул итә.

Статья 74

1. Район Башкарма комитеты, аның җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, дәүләт хезмәтендәге шәхесләр, канун белән башка нәрсә каралмаган булса, район Советы, аның комиссияләре, район Советы депутаты мөрәҗәгате буенча район Советы карамагында булган мәсьәләләр буенча соралган мәгълуматны бирергә тиеш, ә канунны, муниципаль хокук актларын бозу күрсәтелгән

очракта, кичекмәстән хаталарны бетерү  һәм гаеплеләрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә тиеш.

Статья 75

1. Район Советының даими комиссияләре җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесләрен тыңларга хокуклы, район Советы карамагында булган мәсьәләләр буенча материаллар һәм кирәкле документларны таләп итеп алырга хокуклы.

2. Җирле үзидарәнең дәүләт хезмәтендәге шәхесләрен тыңлау нәтиҗәләреннән соң даими комиссия карар кабул итә.

17 бүлек. Депутатларның сайлаучылар белән эшләүе.

Статья 76. Район Советы депутаты гамәлдәге канун, әлеге Регламент һәм район Уставы тарафыннан бирелгән барлык хокуклардан файдалана.

Статья 77. Район Советы депутаты сайлаучылардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карап чыга, үзенең вәкаләтләре кысаларында аларда булган сорауларны вакытында чишүгә булышлык итә, гражданнарны кабул итүне алып бара, җәмәгать фикерен өйрәнә, җирле үзидарәнең тиешле органнарына, ә кирәк булганда – башка дәүләт һәм җәмәгать органнарына тәкъдимнәр кертә.

Статья 78. Район Советы депутатына аның сайлау округында  район Башлыгы тарафыннан вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен, мөмкинлек булганда,сайлаучылар белән очрашулар оештыру өчен, аларга хәбәр итү өчен һәм башка мәсьәләләр буенча тиешле ярдәм күрсәтелә.

Статья 79. Район Советы депутаты сайлаучыларга үзенең эшчәнлеге турында алар белән очрашу вакытында, шулай ук массакүләм мәгълумат чаралары аша белдереп тора.

$15^1$ бүлек.  Югары Ослан муниципаль районы Советының Гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл режимы чорында эш үзенчәлекләре

Статья $79^1$

1. Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл кертелгән чорда район башлыгы тарафыннан район Советы эшенең аерым тәртибе билгеләнә (алга таба – эшнең аерым тәртибе).

2. Әлеге Регламентның район Советы, район Советының даими комиссияләре утырышлары, тавыш бирү һәм аларда карарлар кабул итү өлешендә әлеге Регламентның аерым тәртибен билгеләгәндә әлеге бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.

3. Район Советы утырышы, район Советының даими комиссияләре утырышлары мәгълүмати-телекоммуникацион элемтә челтәрләрен кулланып, видеоконференцэлемтә рәвешендә (алга таба – район Советы утырышы, район Советының даими комиссияләре дистанцион формада) үткәрелергә мөмкин.

Статья $79^{2}$

1. Район Советының даими комиссиясе утырышын дистанцион рәвештә уздыру турында карар район Советы рәисенең мәҗбүри хәбәре белән даими комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә.

2. Әлеге комиссия әгъзалары булмаган затларның дистанцион рәвештә район Советының даими комиссиясе утырышында катнашуы район Советының даими комиссиясе рәисе карары буенча гамәлгә ашырыла.

3. Район Советының даими комиссиясе карарлары дистанцион рәвештә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу утырышта катнашучы район Советының даими комиссиясе әгъзаларын сораштыру (кулны күтәрү) юлы белән үткәрелә.

Статья $79^{3}$

1. Район Советы утырышында катнашу мөмкинлеге район Башкарма комитеты җитәкчесе, район прокуроры тарафыннан мәҗбүри тәртиптә тәэмин ителә.

2. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турындагы мәгълүмат аны үткәрү алдыннан бер көннән дә соңга калмыйча район Советы депутатларына җибәрелә һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Район Советы утырышында карарлар дистанцион рәвештә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу, чыгышка язылу утырышта катнашучы депутатлардан сораштыру (кулны күтәрү) юлы белән башкарыла.

4. Район Советы утырышын дистанцион формада Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм кирәк булган очракта, шулай ук «Интернет» челтәрендәге башка мәгълүмати ресурсларда трансляцияләү мөмкин.

5. Чакырылган затлар, элемтәнең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып, дистанцион рәвештә район Советы утырышында катнаша.

Статья $79^{4}$

1. Район Советы утырышы, район Советының даими комиссиясе утырышы дистанцион формада үткәрелгәндә, утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

2. Район Советы утырышы беркетмәсенә, районның даими комиссиясенә дистанцион формада утырышны үткәргәндә, утырышның башлану һәм тәмамлану вакыты, үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары турында белешмәләр, шулай ук әлеге Регламентта каралган башка белешмәләр кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио-видеоязмасы кушымта итеп бирелә.

16 бүлек. Югары Ослан муниципаль районының әлеге Регламентның үтәлешен контрольдә тотуы

Статья 80. Әлеге регламентның үтәлешен контрольдә тоту Югары Ослан муниципаль районы Башлыгына йөкләнә.

17 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

Статья 81

1. Бу Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр катнашучы депутатлар санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

2. Бу Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләрне карап чыгу һәм кабул итү бу Регламентның 8 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Башлыгы М.Г. Зиатдинов